**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4329**
**26.05.2023**

Башкарма комитетның 2013 елның 17 июлендәге 4258 номерлы карары белән расланган юридик затларга архивлар эшендә һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 17 июлендәге 4258 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 28 июнендәге 3317 номерлы, 2018 елның 20 июнендәге 3512 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 7680 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган юридик затларга архивлар эшендә һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.17 пунктны төшереп калдырырга;

2) 3.3.2 пунктны төшереп калдырырга;

3) 3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Бүлекнең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече гамәлгә ашыра:

1) гаризаны кабул итүне;

2) гаризаларны теркәү журналына гаризаны теркәүне;

3) гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булуга гаризаны тикшерүне.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, гариза бирүче гаризаны шәхсән тапшырганда, бүлек белгече гариза бирүчегә бирелгән керүче номер турында хәбәр итә.

Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, бүлек белгече гариза бирүчегә ачыкланган кимчелекләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза (гариза бирүченең мөрәҗәгате) кергәннән соң 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза.»;

4) 3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Гариза бирүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә яисә почта аша норматив документлар проектларын, исемлекләрне Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә билгеләнгән срокларда бүлеккә бирә (җибәрә).»;

5) 5.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә, Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.»;

6) кушымтаны (белешмә) кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми

хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 26 маендагы
4329 номерлы карарына
кушымта

Юридик затларга архивлар эшендә һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмә)

Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты архив бүлеге

| № т/б | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1. | Башкарма комитет эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең архив бүлеге башлыгы | 30-55-78 | Hazryatova.NM@tatar.ru |
| 2. | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе архив бүлегенең әйдәүче белгече | 30-58-13 | |
| 3. | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе архив бүлегенең 1 категорияле белгече | 30-58-13 | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева